**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**

**Старочелнинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Иске Чаллы авыл Жирлеге**

**СОВЕТЫ**

Адрес: 422876, РТ, с. Старые Челны, ул. Центральная, 20
тел: : 8 (84346) 79-4-53

Адресы: 422876, РТ, Иске Чаллы авылы, Үзәк ур. 20
факс: 8 (84346) 79-4-53

РЕШЕНИЕ    Иске Чаллы авылы    КАРАР

2025 нче елның 30 нчы гыйнвары    107 №

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге Советының
кайбер карарларының үз көчен югалтуын
тану турында

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Иске Чаллы авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

-2014нче елның 29 нчы декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 36нчы номерлы карарын;

-2018нче елның 31нче маендагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында "гы 2014нче елның 29нчы декабрендәге 36нчы номерлы Иске Чаллы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 11нче номерлы карарын;

-2015нче елның 3нче февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 6а нчы номерлы карарын;

-2019нчы елның 11нче ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Советының 2015нче елның 3нче февралендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында"гы 6а нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 20нче номерлы карарын;

- 2017нче елның 28нче августындагы "«Физик затлардан җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында» 23нче номерлы карарын;

- 2020нче елның 10нчы июнендәге «Физик затлардан җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану турында" 9нчы номерлы карарын;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының http:pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм урнаштыру юлы белән Әлки муниципаль районының рәсми сайтында халыкка чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы<br>
Әлки муниципаль районы<br>
Иске Чаллы авыл җирлеге<br>
Советы Рәисе урынбасары

Р.К. Гарипов